| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2021 ел № 35

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 апрелендә кабул ителгән 85 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертелү сәбәпле, 06.10.2003 елның № 131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон нигезендә, Норма авыл җирлеге Уставына таянып, прокуратура күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 апрелендә кабул ителгән 85 номерлы « Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Радик Наиловичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов